# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

К А Р А Р

26 март 2024 ел № 123

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 3 мартындагы 25-ФЗ Федераль закон, "Муниципаль хезмәт турында" 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының " Татар Чаллысы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 февралендәге 75 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.4 бүлегенең 1 пунктындагы 8 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яки) хезмәттә булган вакытта ялган документлар һәм (яки) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулаучы чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру, яки муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында документлар һәм (яки) мәгълүматлар тапшырмау;»

1.2. 3.3 бүлегенең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 3 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 нче маддәсендә каралган анкетада булган белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, эш бирүче (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба анкетада булган мәгълүматлар)»;

1.3. 4.1 бүлекнең 3 пунктының 2 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"2007 елның 3 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясы белән каралган анкета;».

1.4. 4.1 бүлегенең 4 пункты үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 3 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин»;

1.5. 8.1 пунктының 11 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. муниципаль хезмәткә кергәндә һәм хезмәттә булган вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының

рәсми сайтында www.mendelevsk.tatar.ru " Татар Чаллысы авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-мәдәни мәсьәләләр һәм депутат этикасы буенча даими комитетка йөкләргә.

Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы рәисе Т.П. Кузнецова